КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 31 гыйнвар г.Казань № 51

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алу кагыйдәләрен һәм тәртибен раслау турында» 2005 ел, 15 апрель, 190 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 2 август, 366 нчы; 2010 ел, 3 февраль, 53 нче; 2011 ел, 12 октябрь, 847 нче; 2013 ел, 16 сентябрь, 659 нчы; 2014 ел, 19 август, 599 нчы; 2015 ел, 13 апрель, 250 нче, 2015 ел, 12 сентябрь, 669 нчы, 2017 ел, 30 сентябрь, 740 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алу кагыйдәләренә һәм тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

22 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 ел, 27 декабрь, ТРЗ-69 нчы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру һәм республика дәүләт ярдәме кысаларында торак бирү тәртибен камилләштерү буенча алга таба чаралар хакында» 2007 ел, 2 август, 366 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 8 октябрь, 543 нче; 2010 ел, 3 февраль, 53 нче; 2011 ел, 12 октябрь, 847 нче; 2013 ел, 14 май, 321 нче; 2013 ел, 16 сентябрь, 659 нчы; 2013 ел, 29 октябрь, 806 нчы; 2015 ел, 15 гыйнвар, 7 нче; 2015 ел,

13 апрель, 250 нче; 2016 ел, 19 август, 576 нчы, 2016 ел, 5 декабрь, 892 нче, 2017 ел, 30 сентябрь, 740 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Социаль ипотека буенча торак алу өчен гражданнарның түләүләрен кичектереп тору шартларын һәм срокларын билгеләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

«12. Социаль ипотека программасында катнашучылар социаль ипотека шартнамәсе буенча бурычның калган өлешен махсуслаштырылган оешма («Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасы) белән сайлап алынган торак урынын сату-алу шартнамәсе төзү юлы белән кредит оешмаларының заем акчалары хисабына түли алалар, шул ук вакытта элек социаль ипотека шартнамәсе буенча җыелган акчалар һәм дәүләт ярдәме түләүләре сату-алу шартнамәсе буенча беренчел кертем сыйфатында күчерелә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин